**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КРАСНОСЕЛЬСКИЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

422700, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Биектау тимер юл станциясе поселогы, Совет урамы, 13

**СОВЕТ КРАСНОСЕЛЬСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422700, Республика Татарстан, Высокогорский район,
п. ж/д ст. Высокая Гора, ул. Советская, 13

тел./факс 8(84365) 2-35-82,e-mail: Ksel.Vsg@tatar.ru

---

**КАРАР** — **РЕШЕНИЕ**

**25 ноябрь 2024 ел** — **№ 111**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге Советының 2015 елның 15 октябрендәге 7 нче номерлы «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге, 2014 елның 30 октябрендәге 82-ТРЗ номерлы «Салым салу объектларының кадастр бәясеннән чыгып, физик затлар мөлкәтенә салым буенча салым базасын билгеләү тәртибен Татарстан Республикасы территориясендә куллана башлауның бердәм датасын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге Советы

**КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге Советының 2015 елның 15 октябрендәге 7 нче номерлы «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» карарына (2018 елның 4 маендагы 81 нче номерлы, 2018 елның 13 сентябрендәге 91 нче номерлы, 2018 елның 21 декабрендәге 110 нчы номерлы, 2022 елның 25 ноябрендәге 59 нчы номерлы, 2023 елның 15 сентябрендәге 74 нче номерлы, 2023 елның13 ноябрендәге 79 нчы номерлы Совет карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктның 4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) 2,5 процент:

һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып киткән салым салу объектларына карата;»

1.2. 2 пунктның 6 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2025-2027 елларда 1,2 процент, 2028 елдан 2% :

Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 7 пункты нигезендә билгеләнә торган исемлеккә кертелгән салым салу объектларына; Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 10 пунктының икенче абзацында каралган салым салу объектларына карата.»

2. Әлеге карар законлы көченә 2025 елның 1 гыйнварыннан, әмма ул рәсми рәвештә игълан ителгән көннән кимендә бер ай узгач керә

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең Интернет челтәрендәге рәсми сайтында https://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ адрес буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

Совет Рәисе,
Красносельский авыл җирлеге Башлыгы — Р.Ф. Хисаметдинов